ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законының 20 һәм 22 статьяларына һәм «Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 31-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты тарафыннан кертелгән «Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законының 20 һәм 22 статьяларына һәм «Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 31-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2024 елның 23 декабре
№ 157-VII ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советының
Социаль сәясәт
комитеты тарафыннан
кертелә

**«Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законының 20 һәм 22 статьяларына һәм «Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәрешләр кертү хакында»**

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ЗАКОНЫ

## 1 статья

«Физик культура һәм спорт турында» 2008 елның 8 октябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 10 (I өлеш); 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 5; 2012, № 7 (I өлеш), № 12 (II өлеш); 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 1 – 2, № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 3, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2016, № 3, № 10; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 27 (I өлеш); 2018, № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2020, № 87 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 49 (I өлеш); 2022, № 24 (I өлеш), № 34 (I өлеш); 2024, № 28 (I өлеш), № 34 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 20 статьяның 1 өлешендәге 1 пунктында «физкультура, спорт, реабилитация һәм гражданнарның физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүләренә бәйле рәвештә башка чаралар үткәрү;» сүзләрен «физкультура, спорт, реабилитация, абилитация чаралары һәм гражданнарның физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүләренә бәйле рәвештә башка чаралар үткәрү» сүзләренә алмаштырырга;

2) 22 статьяда:
а) исемдә «физик реабилитацияләү» сүзләреннән соң «һәм абилитацияләү» сүзләрен өстәргә;
б) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«1. Инвалидларны һәм сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән затларны, спортны, адаптив физик культура һәм адаптив спорт чараларын һәм алымнарын кулланып, кеше организмының бозылган йә булмаган функцияләрен һәм инвалидларның һәм сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән затларның көнкүреш эшчәнлегенә, иҗтимагый һәм һөнәри эшчәнлегенә сәләтләрен торгызуга яисә булдыруга юнәлдерелгән чаралар (шул исәптән физкультура-савыктыру чаралары) һәм хезмәт күрсәтүләр комплексыннан файдаланып, инвалидларны һәм сәламәтлеге

мөмкинлекләре чикләнгән затларны физик реабилитацияләү һәм абилитацияләү һәм инвалидларны социаль адаптацияләү реабилитацияләү оешмаларында, инвалидларның физкультура-спорт клубларында, физкультура-спорт оешмаларында һәм инвалидларны комплексны реабилитацияләү һәм абилитацияләү системасының дәүләтнеке булмаган оешмаларында гамәлгә ашырыла.»;

в) 2 өлештә «физик реабилитацияләүнең» сүзләреннән соң «һәм абилитацияләүнең» сүзләрен өстәргә;

г) 3 өлештә «физик реабилитацияләүгә» сүзләреннән соң «һәм абилитацияләүгә» сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

«Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2014 елның 18 декабрендәге 126-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2014, № 12 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 57 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 92 (I өлеш), «медицина,» сүзен «реабилитация, медицина ярдәме» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

**3 статья**

1. Әлеге Закон 2025 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законының 20 һәм 22 статьяларына һәм «Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**

**АҢЛАТМА**

«Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законының 20 һәм 22 статьяларына һәм «Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 25 декабрендәге 651-ФЗ номерлы Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә эшләнде.

Үзгәрешләр инвалидларны реабилитацияләү һәм абилитацияләү буенча төрле закон актларында каралган хезмәтләрне комплекслы күрсәтүгә кагылышлы нормаларны төгәлләштерүгә юнәлдерелгән.

**«Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законының 20 һәм 22 статьяларына һәм «Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы кабул ителүгә бәйле рәвештә үз көчен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законының 20 һәм 22 статьяларына һәм «Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарының һәм башка норматив хокукый актларының үз көчләрен югалтуын тануны, аларны туктатып торуны, үзгәртүне яисә башкаларын кабул итүне таләп итми.

**«Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законының 20 һәм 22 статьяларына һәм «Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына финанс-икътисадый нигезләү**

«Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законының 20 һәм 22 статьяларына һәм «Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә өстәмә чыгымнарны таләп итми.